**СОВЕТ ЕГОРЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422621 д.Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422621 Каип авылы,
Эзэк урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

---

2020елның 13ноябре 16 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Кызыл Ил торак пункты гражданнары җыенының карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Кызыл Ил торак пункты гражданнары җыены карар кабул итте**:**

1. Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Кызыл Ил торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидлар керми.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.:

- Кызыл Ил торак пунктында контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Егорьево авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _________________ Р.Ж.Хәмидуллин

Егорьево авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе _________________ Р.Ж.Хәмидуллин